ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.12.2020 с.Старое Дрожжаное № 680

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының " Советлар Союзы Герое Семен Артемьевич Уганин исемендәге Матак урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 14 августындагы 407 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Семен Артемьевич Уганин исемендәге Матак урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына, 1.10 пунктны түбәндәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1.10. Укучыларны тукландыруны оештыру белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәктәпкә йөкләнә һәм укучыларның туклануын оештыру турындагы нигезләмә белән җайга салына.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет җитәкчесе: Д. Ә. Сатдинов